**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2024 елның 8 феврале №1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында гражданнар җыенының 2023 елның 18 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 1 номерлы карарына үзгәреш кертү турында**

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы карарында кертелгән техник хата белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлеге Шөгер торак пункты гражданнары җыенының 2023 елның 18 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында гражданнар җыенының 2023 елның 18 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Карарның преамбуласында «Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 1493 кеше.» абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1493 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 795 кеше.».

2.Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров ур., 17 йорт административ бина, Киров ур., 23 йорт, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин урамындагы 3 нче Энергорайон, Ленин урамы, 32 йорт, Шөгер авылы мәдәният йорты, Ленин урамы, 35 йорт, Шөгер участоок хастаханәсе, Горький урамы, 4 йорт адресы буенча урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Шөгер авыл җирлеге башлыгы Р.Н.Гафиятуллин